**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены карары**

15.11.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту. - каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү; - Тимбай авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге чорда үләннәрне чабу, кышкы чорда карны чистарту, ДТ сатып алуга , запас частьләр сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тимбай авыл җирлеге башлыгы _________ И.Г.Айзатуллин

Халык җыены секретаре _________ Г.А.Хәкимова